**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 457**
**22.10.2019**

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләрен хәл итү максатында, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ Федераль законның 12 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Законының 17.1 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарынннан кайткан затларны ресоциализацияләү эшчәнлеген оештыру турында» 2019 елның 29 июлендәге карары, шәһәр Уставының 53 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

1) иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 22 октябрендәге
М 457 нче карарына
1 нче кушымта

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген коодинацияләүне һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итүен оештыруны тәэмин итүче, даими эшләүче координацион орган булып тора

2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге нигезнамәгә таяна.

3. Ведомствоара комиссиянең эшчәнлеге ресоциализацияләүдә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның иреклелеге һәм ихтыяр белдерү иреге принципларына нигезләнә.

2 бүлек. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

4. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәрендә иректән мәхрүм ителү рәвешендә җинаять җәзасы үтеп кайтучы яисә җинаять- хокукый характердагы башка чараларга тартылучы затларны җәмгыятькә реинтеграцияләү максатында социаль-икътисадый, педагогик, хокук характерындагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

- ярдәм күрсәтү;
- һөнәри ориентация һәм хезмәт адаптациясе;
- торак һәм көнкүреш мәсьәләләрен җайлау;
- медицина ярдәме;
- психологик ярдәм;
- туганнары белән һәм башка югалган социаль элемтәләрне торгызуга ярдәм итү;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләүнең башка формалары;

2) иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, башкарма хакимият федераль органнарының территориаль органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итү;

3) җинаятьчелекнең кабатлануын (рецидив) профилактикалау;

4) Яр Чаллы шәһәре территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү һәм хезмәт реинтеграциясе буенча үткәрелә торган эш турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итеп тору.

## 3 бүлек. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

5. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) ресоциализациядә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның индивидуаль тәртиптә социаль хәлен тикшерә һәм анализлый;

2) законда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм күрсәтү механизмнарын, башка оешмаларның һәм гражданлык җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләүнең индивидуаль программасын төзи. Реабилитация программасында каралган чараларның һәрберсенең үтәлеше өчен җаваплы затларны, аларны тормышка ашыру срокларын билгели;

3) ресоциализация буенча үткәрелгән чараларның йомгакларын һәм нәтиҗәлелеген анализлый;

4) ресоциализациянең индивидуаль программасын тормышка ашыруны туктату турында карар кабул итә:

- тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешкәндә;

- зат Яр Чаллы шәһәреннән башка даими яшәү урынына киткәндә (зат Татарстан Республикасындагы башка муниципаль районга (шәһәр округына) киткән очракта), бу факт турында мәгълүмат әлеге затка караган материаллар белән бергә Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районының (шәһәр округының) ведомствоара комиссиясенә җибәрелә;

- заттан ресоциализациядә ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында гариза кергәндә;

- ресоциализациянең индивидуаль программасын алга таба тормышка ашыру мөмкин булмаган башка очракларда;

5) Яр Чаллы шәһәрендә кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазифаи затларга җибәрә.

6. Ведомствоара комиссия түбәндәге хокукларга ия:

1) үз компетенциясе чикләрендә Яр Чаллы җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыяте институтлары тарафыннан үтәргә тәкъдим ителгән карарлар кабул итәргә;

2) хокук саклау органнарына гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы сорауларны хәл итү өчен тиешле документлар һәм материаллар җибәрергә, җинаять җаваплылыгына яки административ җаваплылыкка китерүче закон бозу билгеләре ачыкланган очракта.

## 4 бүлек. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

7. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында формалаштырыла. Ведомствоара комиссия составы Яр Чаллы шәһәре Хакиме карары белән раслана.

8. Комиссия рәисе:

1) ведомствоара комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) хәлиткеч тавышка ия булып, ведомствоара комиссия утырышларын алып бара;

3) ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

4) комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында эшләр куша;

5) ведомствоара комиссия кабул иткән документларга кул куя;

6) ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен персональ җаваплылык тота.

9. Комиссия секретаре:

1) комиссия рәисе кушкан эшләрне үти;

2) ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле документларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышының беркетмәсен алып бара;

3) ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга утырышның урыны, үткәрү вакыты һәм Ведомствоара комиссиянең көн тәртибе турында мәгълүмат җиткерә, аларны тиешле материаллар белән тәэмин итә;

4) затның азат ителәчәге, аның торак урыны булуы, эшкә яраклылыгы һәм булган белгечлекләре турында җәзаларны үтәтү системасы учреждениеләре администрацияләреннән килүче мәгълүматны җыя һәм гомумиләштерә;

5) иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализацияләүдә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кабул итә;

6) ресоциализация программасында катнашучы һәркемгә ярдәм күрсәтү картасы һәм шәхси дело ача, аңа ресоциализацияләүнең индивидуаль программасын үтәү буенча документлар һәм материаллар кертелә;

7) муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидаә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазифаи

затлардан ведомствоара комиссиянең эшчәнлеге өчен кирәк булган материалларны һәм мәгълүматны сорый;

8) ведомствоара комиссия утырышының беркетмәләрен тутыра;

9) утырышлар нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия рәисе кушкан эшләрне башкаруны оештыра;

10) Яр Чаллы шәһәре халкына ведомствоара комиссиянең функцияләрен һәм аның эшчәнлеге нәтиҗәләрен хәбәр итүне оештыра.

10. Ведомствоара комиссия утырышларында Яр Чаллы шәһәре прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешенү буенча).

11. Ведомствоара комиссия утырышларына ведомствоара комиссия составына керми торган дәүләт хакимияте органнары, Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыятьләре институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

12. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычында башкарыла.

## 5 бүлек. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

13. Ведомствоара комиссиянең эше даими нигездә алып барыла.

14. Ведомствоара комиссиянең утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациядә ярдәм күрсәтү турында гаризалар керүгә карап үткәрелә. Кирәк булган очракта, ведомствоара комиссия рәисенең, аның урынбасарының, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасының инициативасы буенча (ведомствоара комиссия рәисе белән килешенү һәм секретаре тәкъдим итү буенча) ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

15. Ведомствоара комиссия утырышларын комиссия рәисе алып бара, ул булмаганда яки аның кушуы буенча – комиссия рәисе урынбасары.

16. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында ресоциализациядә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашуы максатка яраклы дип табылган башка затларга утырыш көненә кадәр кимендә бер тәүлек алдан хәбәр ителә.

17. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында Яр Чаллы шәһәре прокурорына хәбәр ителә.

18. Ведомствоара комиссия утырышы аның составының яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы була.

19. Ведомствоара комиссиянең карарлары рекомендация характерында була һәм утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

20. Утырышларда каралучы мәсьәләләр буенча фикер алышканда ведомствоара комиссия әгъзалары тигез хокукка ия.

21. Ирektән мәхрүм итү урыныннан кайткан затның теләге буенча утырыш әлеге нигезнамәнең 11 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча үткәрелә.

22. Комиссия әгъзаларының утырышта каралган мәсьәләләр турында мәгълүматны әлеге мәсьәләләргә кагылышы булган затларның рөхсәтеннән башка таратырга хаклары юк.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен комиссия әгъзалары закон нигезендә җавап тоталар.

23. Ведомствоара комиссиянең эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән масакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүматларны персональ мәгълүматларны күрсәтмичә бирергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 22 октябрендәге
М 457 нче карарына
2 нче кушымта

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

| т/с | Ф.И.А.и. | вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Абдуллин Ринат Әзһәр улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Мингалиев Рәүф Минрәхим улы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 4. | Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| 5. | Әлмөхәммәтова Елена Юрьевна | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы урынбасары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| 6. | Белова Мария Николаевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе башлыгы урынбасары (килешенү буенча) |
| 7. | Бәдретдинов Руслан Фәрит улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы урынбасары – полиция башлыгы (килешенү буенча) |
| 8. | Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы | ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешенү буенча) |
| 9. | Быданова Татьяна Александровна | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешенү буенча) |
| 10. | Скибина Татьяна Александровна | Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы урынбасары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| 11. | Викулов Сергей Михайлович | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең миграция мәсьәләләре бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 12. | Галиәкбәров Сирень Фатыйх улы | ТР буенча ФКХ идарәсе башлыгы урынбасары - ТР буенча ФКХИ Яр Чаллы шәһәрендәге хезмәте башлыгы (килешенү буенча) |
| 13. | Кирилова Вера Александровна | Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы урынбасары, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге башлыгы |
| 14. | Красников Валерий Александрович | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенең полиция участок вәкаләтлеләре һәм балигъ булмаганнар белән эшләү бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| 15. | Зарипов Айдар Салават улы | ТР буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең җинаять – башкару инспекциясе ФКУ Яр Чаллы шәһәре Комсомол районы буенча филиалы башлыгы |
| 16. | Зарипова Равилә Гыйльметдин кызы | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы Гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» МКУ башлыгы |
| 17. | Минегалиев Мөдәрис Харис улы | Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 18. | Мифтахова Гөлнара Фәнир кызы | «Перекресток» билгеле яшәү урыны һәм шөгыле булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәге» ДАСХКУ директоры (килешенү буенча) |
| 19. | Мифтахова Эльвира Рәшит кызы | «Ышаныч» халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге» ДАСХКУ директоры (килешенү буенча) |
| 20. | Ситдыйков Салават Әнәс улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 21. | Фәйсханов Рамил Рәшид улы | Хаким ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) |
| 22. | Фролова Ирина Васильевна | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 23. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 24. | Шәфигуллина Олеся Рәдиф кызы | ТР буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең җинаять – башкару инспекциясе ФКУ Яр Чаллы шәһәре Автозавод районы буенча филиалы башлыгы |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева